ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.12, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Совет мәйданы, 12 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-00-44, факс (84366)3-11-44. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

# КАРАР

« 08 » декабрь 2021 ел № 2214

**2022-2025 елларга Арча муниципаль районында хезмәт шартларын яхшырту һәм хезмәтне саклау буенча озак сроклы максатчан программаны раслау турында**

«Татарстан Республикасында хезмәтне саклау турында» 1997 елның 10 декабрендәге 1417 номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә һәм «Татарстан Республикасында хезмәтне саклау өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру турында» 2008 елның 10 ноябрендәге 799 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезләмәләрен гамәлгә ашыру кысаларында Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. 2022-2025 елларга Арча муниципаль районында хезмәт шартларын һәм хезмәтне саклауны яхшырту буенча озак сроклы максатчан программаны (алга таба - Программа) кушымта нигезендә расларга.

2. Район предприятиеләренә, учреждениеләренә һәм оешмаларына Программаны гамәлгә ашыру чараларын күрергә.

3. Хезмәтне саклау буенча координация советына, муниципаль районның башкарма комитетына ел саен 1 мартка кадәр Программаны үтәү барышы турында мәгълүмат тапшырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Арча муниципаль районы рәсми сайтында (htt:arsk.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары - хезмәтне саклау буенча координация советы рәисе Вафина Эльвира Шамил кызына йөкләргә.

Җитәкче вазыйфаларын башкаручы И.Ә.Галимуллин

Арча муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесенең
08.12. 2021 ел, №2214
карары белән расланды

# 2022-2025 елларга Арча муниципаль районында хезмәт шартларын яхшырту һәм хезмәтне саклау буенча озак сроклы максатчан программа

# ПРОГРАММАНЫҢ ПАСПОРТЫ

| | |
|---|---|
| Программаның исеме | 2022 - 2025 елларга Арча муниципаль районында хезмәт шартларын яхшырту һәм хезмәтне саклау буенча озак сроклы максатчан программа (алга таба - Программа) |
| Программаны эшләү өчен нигез | Россия Федерациясе Хезмәт кодексы; «Татарстан Республикасында хезмәтне саклау турында» 1997 елның 10 декабрендәге 1417 номерлы Татарстан Республикасы Законы; «Татарстан Республикасында хезмәтне саклау өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары |
| Программаның заказчысы | АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
| Программаны төп эшләүчеләр | Арча муниципаль районы Башкарма комитетының Хезмәтне саклау буенча координация советы |
| Программаның максаты | Арча муниципаль районы территориясендә урнашкан оешмалар хезмәткәрләренең һөнәри имгәнүләрен киметү максатларында хезмәт шартларын яхшырту һәм хезмәтне саклау |
| Программаның бурычлары | 1. Хезмәтне саклауның дәүләт идарәсе системасын үстерү.<br>2. Укытуның заманча технологияләре нигезендә хезмәтне саклау хезмәткәрләрен әзерләү.<br>3. Хезмәтне саклауны мәгълүмати тәэмин итү һәм пропагандалау. |
| Программаны гамәлгә ашыру вакыты | 2022-2025 еллар |
| Программаны еллар буенча финанслау күләмнәре һәм чыганаклары | Программаны район бюджетыннан һәм Арча муниципаль районы предприятиеләре акчаларыннан финанслауның гомуми күләме - 61383,0 мең сум, шул исәптән район бюджетыннан - 120,0 мең сум:<br>2022 елда -14729,0 мең сум, шул исәптән район бюджетыннан - 30,0 мең сум;<br>2023 елда -15129,0 мең сум, шул исәптән район бюджетыннан - 30,0 мең сум;<br>2024 елда-15527,0 мең сум, шул исәптән район бюджетыннан - 30,0 мең сум.<br>2025 елда-15998,0 мең сум, шул исәптән район |

бюджетыннан - 30,0 мең сум.

| | |
|---|---|
| Программаны гамәлгә ашыруның көтелгән соңгы нәтиҗәләре (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары) һәм аның нәтиҗәлелеге күрсәткечләре | 1. 2025 елга Программа чараларын гамәлгә ашыру түбәндәгеләргә ирешергә мөмкинлек бирәчәк:<br>хезмәтне саклау чараларына чыгымнарны 1 кешегә исәпләгәндә 9500 сумга кадәр арттырырга; производствода зыян күрүчеләр санын 1000 эшләүчегә исәпләгәндә 1,1 кешегә киметергә;<br>җитәкчеләрнең һәм белгечләрнең хезмәтне саклау буенча узган укулары дәрәҗәсен 1000 хезмәткәргә исәпләгәндә 29,50 кешегә кадәр арттырырга.<br>2. Социаль нәтиҗә:<br>производствода бәхетсезлек очраклары һәм һөнәри авырулар куркынычын киметергә; произвлдствода имгәнүләр һәм һөнәри авырулар дәрәҗәсен киметергә; хезмәткәрләрне зарарлы һәм куркыныч җитештерү факторлары йогынтысыннан яклау дәрәҗәсен арттырырга; имин булмаган хезмәт шартларында эшләүче хезмәткәрләр санын кыскартырга.<br>3. Социаль-икътисади нәтиҗә:<br>производствода бәхетсезлек очракларыннан, производство белән бәйле авырулардан, һөнәри авырулардан зыян күргән хезмәткәрләрнең сәламәтлеген торгызуга матди чыгымнарны киметергә; производствода бәхетсезлек очраклары һәм һөнәри авырулар нәтиҗәсендә хезмәткәрләргә китерелгән зыянны каплауга чыгымнарын киметергә; зарарлы һәм куркыныч, авыр хезмәт шартларында эшләгән өчен тапламалар һәм компенсацияләр бирүгә чыгымнарны киметергә;<br>моңа бәйле рәвештә производствода имгәнүләр яки һөнәри авыру һәм сәламәтлек саклау өлкәсендә чыгымнар нәтиҗәсендә инвалидлык дәрәҗәсен кимететергә; эш вакытын югалтуларны кыскарту исәбенә хезмәт җитештерүчәнлеген арттырырга;<br>имгәнүләр һәм производствога бәйле авырулар аркасында төп хезмәткәрләрне алыштыручы, эш һәм квалификация тәҗрибәсе булмаган вакытлы хезмәткәрләр тарафыннан ватылган җиһазларны ремонтлау һәм алмаштыру чыгымнарын кыскартырга. |

## I.Озак сроклы максатчан программа хәл итәчәк проблеманың үзенчәлеге

Хезмәтне саклау хезмәт эшчәнлеге барышында гражданнарның гомерен һәм сәламәтлеген саклауның мөһим шарты булып тора. Хезмәтне саклау өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыруга, эшләү дәверендә кешенең иминлеген, сәламәтлеген һәм эшкә сәләтлелеген тәэмин итү буенча хокукый, социаль-икътисади, оештыру-техник, санитар-гигиена, дәвалау-профилактика һәм башка чараларны гамәлгә ашыруга юнәлдерелгән дәүләт идарәсе системасы.

Арча муниципаль районында хезмәтне саклау дәүләт идарәсе Россия Федерациясе Конституциясе, Россия Федерациясе Хезмәт кодексы, Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив актларының тиешле нормалары нигезендә гамәлгә ашырыла.

Хезмәтне саклау белән идарә итү системасында Хезмәтне саклау буенча координация советына (алга таба - Совет) аерым роль бирелә, бу өлкәдә мөһим карарлар кабул ителә. Совет Арча муниципаль районы Башкарма комитеты каршында төзелде. «Арча муниципаль районында хезмәтне саклау өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру турында» Башкарма комитетның 2008 елның 12 декабрендәге 1124 номерлы карары нигезендә Советның бурычлары һәм вәкаләтләре билгеләнде. Совет составы «Арча районы Башкарма комитеты карары белән расланган Хезмәтне саклау буенча координация советы составына үзгәрешләр кертү турында» Башкарма комитетның 19.08.2015 №791, 20.11.2015 №1142, 16.02.2016 №151, 15.11.2018 №1140, 17.02.2020 №101, 28.10.2020 №846, 06.04.2021 №240 карарлары белән билгеләнгән. Комиссия составына республика министрлыкларының, дәүләт күзәтчелеге һәм контроле федераль органнарының, көч структураларының җирле вәкилләре, Арча муниципаль районының һөнәр берлекләре оешмаларының координация советы рәисе керә.

2021 елның 1 гыйнварыннан хезмәтне саклау буенча яңа кагыйдәләр үз көченә керүгә бәйле рәвештә, хезмәт министрының беренче урынбасары һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе катнашында 2021 елның 11 февралендә «Арчаның 6 номерлы урта белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет учреждениесендә оешмалар җитәкчеләре һәм белгечләр катнашында хезмәтне саклау буенча дәүләт норматив таләпләрен билгеләгән төп үзгәрешләр буенча семинар оештырылды.

Арча муниципаль районы предприятиеләрендә хезмәтне саклауны оештыру буенча максатчан эш алып барыла. Эшләүче гражданнарның гомерен һәм сәламәтлеген саклау проблемаларын хәл итү бу юнәлештә эшне оештырудан башка мөмкин түгел. 2022-2025 елларда район предприятиеләрендә хезмәтне саклауны оештыру эшен актив дәвам итәргә ниятлиләр, нәтиҗәдә уңай тенденция күзәтелә. «Ак барс» агрокомплексы», «Яңарыш» АФ», «АЮ» АФ, «Казанка» АФ, «КСМ», «Энергосервис», «Ташкичү», «ТехноАрча» ҖЧҖендә, «Арча район мәдәният йорты» муниципаль бюджет учреждениесендә хезмәтне саклау буенча азат ителгән

белгечләр билгеләнде, ә «Ашыт» , «Кызыл Яр» ЖЧЖендә, Г.Тукай исемендәге Арча педагогия көллиятендә хезмәтне саклау буенча белгеч вазыйфалары башка белгечләргә йөкләнде.

Муниципаль районда хезмәтне, хезмәткәрләрнең гомерен һәм сәламәтлеген саклау өлкәсендә башкарыла торган зур эшкә карамастан, вәзгыять тотрыклы түгел. Дәүләт статистикасы бүлеге мәгълүматларына караганда, 2021 ел белән чагыштырганда 2020 елда производствода бәхетсезлек очракларыннан зыян күргән, 1 эш көненә һәм аннан күбрәк вакытка хезмәткә сәләтен югалткан кешеләр саны кимегән, ә производствода имгәнүләр дәрәҗәсе 0,45 тәшкил иткән, бу 0,24кә югарырак. 2020-2021 елларда хатын-кызлар алган имгәнүләр саны теркәлмәгән.

Производствода бәхетсезлек очраклары нәтиҗәсендә зыян күрүчеләрнең абсолют һәм чагыштырма саны динамикасы 1 нче таблицада күрсәтелде.

1 нче таблица

Арча муниципаль районында производствода имгәнүләр динамикасы
(дәүләт статистикасы бүлеге мәгълүматлары)

| **1 эш көненә һәм аннан да күбрәккә хезмәткә сәләтләрен югалткан һәм үлемгә китергән зыян күрүчеләр саны** | **2018** | **2019** | **2020** | **2021** |
|---|---|---|---|---|
| Барлыгы | 5 | 4 | 2 | 1 |
| 1 000 эшләүчегә исәпләгәндә, | 0,98 | 1,3 | 1,32 | 0,21 |
| шул исәптән хатын-кызлар | 1 | 2 | 0 | 0 |
| яшүсмерләр | 1 | | | |
| алардан үлем белән тәмамланган очраклар: | | | | |
| барлыгы | 1 | 2 | 1 | |
| 1000 хезмәткәргә исәпләгәндә, | 0,195 | 0,425 | 0,439 | |
| шул исәптән хатын-кызлар | | | | |
| яшүсмерләр | | | | |

2021 елның 11 ае эчендә производствода бәхетсезлекнең үлем белән тәмамланган очраклары теркәлмәгән, 1 кеше авыр нәтиҗәләр белән имгәнү алган.

Сәламәтлек һәм имин хезмәт шартлары тудыруда өстенлекле юнәлешләрнең берсе - муниципаль район предприятиеләрендә һәм оешмаларында хезмәт шартларын махсус бәяләү (алга таба - СОУТ) уздыру. Бу эшнең төп элементлары эш урыннарында зарарлы һәм куркыныч факторларны ачыклау, аларның факттагы нәтиҗәләрен бәяләү. Тиешле нормативларга туры

килмәгән очракта, хезмәт шартларын яхшыртуга, зарарлы һәм (яисә) куркыныч хезмәт шартларында эшләү өчен ташламалар һәм компенсацияләр бирүгә юнәлдерелгән чараларны мәҗбүри планлаштыру таләп ителә.

Соңгы 3 елда хезмәт шартларын махсус бәяләү (СОУТ) 34 предприятиедә (1256 эш урыны) үткәрелгән.

2020-2021 елларда хезмәт шартларын махсус бәяләү уздыру белән (СОУТ) актив шогыльләнгән предприятиеләр: Ак Барс агрокомплексы ҖЧҖ – 319 эш урыны, «Северный» АФ» ҖЧҖ - 152, «АРЧА» СП - 100, «Ватан» АФ» ҖЧҖ - 109, «Игенче» ҖЧҖ - 85, «Ташкичү» ҖЧҖ - 54, «ТехноАрск» ҖЧҖ - 54, Арча район мәдәният йорты – 36 эш урыны.

Хезмәт шартларын махсус бәяләүнең нәтиҗәлелеген анализлау һәм бәяләү (СОУТ) максатларында район предприятиеләрендә ел саен хезмәтне саклауның 1 нче формасы буенча «Производствода хезмәтне саклау турында белешмәләр» дигән статистик күзәтү уздырыла.

Хезмәт урыннарында хезмәт шартларын сыйфатлы һәм объектив бәяләү, хезмәтне саклау буенча еллык укулар уздырганда, СОУТ уздыру мәсьәләләренә аерым игътибар бирелә.

Хезмәтне саклауда дәүләт идарәсе системасын үстерү алдагы елларга Арча муниципаль районы җитәкчелегенең мөһим бурычларының берсе булып тора. Әлеге мәсьәләне хәл итү социаль-икътисади сәясәт уздыруда һәм социаль партнерлыкны үстерүдә дәүләт идарәсенең барлык структуралары һәм баскычлары эшчәнлеген координацияләү нигезендә мөмкин. Социаль партнерлык формаларының берсе - районның күп кенә предприятиеләрендә һәм оешмаларында кискен проблемаларны хәл итүгә юнәлтелгән чараларны һәм икътисади мөмкинлекләрне исәпкә алып, хезмәтне саклау буенча конкрет йөкләмәләрне күздә тоткан килешүләр һәм күмәк шартнамәләр төзү. Хезмәткәрләрнең хезмәт иминлеге, аларның тормышы һәм сәламәтлеге хезмәтне саклауга бирелә торган суммага турыдан-туры бәйле. Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 226 статьясы нигезендә хезмәт шартларын яхшырту һәм хезмәтне саклау чараларын финанслау эш бирүченең бурычы булып тора, әмма үз хезмәткәрләренең иминлеге өчен социаль җаваплылык дәрәҗәсе түбән булган җитәкчеләр бу мәсьәләгә тиешле игътибар бирми. Хезмәтне саклау чараларына чыгымнар предприятие җитәкчеләренең хезмәтне һәм үз хезмәткәрләренең гомерен һәм сәламәтлеген саклауга, димәк, хезмәтне саклау белән идарә итүнең гамәлдәге системасы нәтиҗәлелегенә карата мөнәсәбәтләренең яхшы индикаторы.

Дәүләт статистикасы бүлеге мәгълүматлары буенча, 2021 елда район предприятиеләрендә хезмәтне саклау чараларына чыгымнар 35240 мең сум тәшкил иткән яки 1 хезмәткәргә исәпләгәндә - 8520,8 сум, бу 2019 ел белән чагыштырганда 8,1 процентка күбрәк (2 нче таблица).

2 нче таблица

Арча муниципаль районында хезмәтне саклауга тотылган чыгымнар
(дәүләт статистикасы бүлеге мәгълүматлары)

| **2019 ел** | | **2020 ел** | | **2021 ел** | |
|---|---|---|---|---|---|
| барлыгы, мең сум | 1 хезмәткәргә исәпләгәндә, сум | барлыгы, мең сум | 1 хезмәткәргә исәпләгәндә, сум | барлыгы, мең сум | 1 хезмәткәргә исәпләгәндә, сум |
| 18835 | 8035 | 27998.1 | 8271 | 35240 | 8520,8 |

Хезмәтне саклау өлкәсендә массакүләм хокук бозу булып хезмәткәрләрне хезмәтне саклау буенча укытмау һәм инструкцияләмәү тора. Оешма җитәкчеләренең һәм белгечләренең хезмәтне саклау өлкәсендә белеме җитәрлек булмау, максималь табыш алу теләге производствода имгәнүләрнең сәбәбе булып кала бирә.

Соңгы 3 елда -2019 елдан 2021 елга кадәрге чорда -республиканың укыту оешмаларында 227 кеше укыды. Укулар «Арча гуманитар-техник техникумы», «ТИПКА» ФДБМУ һәм «Хезмәтне саклауның төбәкара ассоциациясе» (3 нче таблица) укытучылары тарафыннан үткәрелде.

3 нче таблица

Татарстан Республикасы укыту оешмаларында Арча муниципаль районы предприятиеләре җитәкчеләренең һәм белгечләренең хезмәтне саклау буенча укучылар саны динамикасы

| Күрсәткеч | 2019 ел | 2020ел | 2021 ел |
|---|---|---|---|
| Хезмәтне саклау буенча өйрәтелгән кешеләр саны, кеше | 90 | 92 | 45 |

Имин хезмәт шартлары тудыру, имгәнүләрне булдырмау хезмәтне саклауны оешкан төстә мәгълүмати тәэмин итүгә һәм пропагандалауга, кешеләрнең тормыш позицияләренә йогынты ясый торган эмоциональ халәт формалаштыруга турыдан-туры бәйле. Хезмәтне саклау мәсьәләләрен пропагандалау ысуллары күптөрле булса да, ахыргы максат - хезмәткәрләрдә имин эшләү өчен куелган таләпләрне үтәү кирәклеген, имин эшләргә ярдәм итә торган сыйфатлар тәрбияләү, хезмәтнең куркынычсызлы мәсьәләләренә карата уңай мөнәсәбәт тудыру. Статистик мәгълүматларны анализлау күрсәткәнчә, оештыру сәбәпләре аркасында килеп чыккан бәхетсезлек очраклары техник сәбәпләр аркасында туган бәхетсезлек очракларыннан күбрәк. Пропаганда эшчәнлегенең төп формасы булып җитәкчеләр, белгечләр һәм эшчеләр алдында хезмәт куркынычсызлыгы тематикасы буенча

лекцияләр, семинарлар, киңәшмәләр, белгечләр белән очрашулар, смотр-конкурслар кебек формаларны файдаланып, лекторлар чыгышлары тора. Арча муниципаль районы Башкарма комитеты МАОТның ел саен 28 апрельдә Бөтендөнья хезмәтне саклау көне үткәрү инициативасын хуплый. Районның барлык предприятиеләре һәм оешмалары аны үткәрүне актив хупладылар. Акция кысаларында семинарлар, оешмалар җитәкчеләре һәм белгечләре белән киңәшмәләр, хезмәтне саклау һәм хезмәт шартлары өлкәсендәге проблемалар буенча фикер алышулар узды. Район предприятиеләрендә хезмәтне саклау һәм куркынычсызлык айлыклары игълан ителде.

Массакүләм мәгълүмат чараларында хезмәтне саклау мәсьәләләрен яктырту хезмәт иминлеген пропагандалауның мөһим чарасы булып тора. Районның эш бирүчеләре һәм белгечләренә хезмәтне саклау буенча мәгълүмати-аналитик бюллетеньнәр тарату зур популярлык казанды.

Хезмәтне саклау мәсьәләләрен мәгълүмати тәэмин итү һәм пропагандалау чаралары хезмәтне саклау таләпләрен үтәү өчен эшләүчеләрнең җаваплылыгын арттыруга ярдәм итә, бу исә производствода гомуми имгәнүләрнең кимүенә китерә.

Район Советы тарафыннан ел саен хезмәт шартларын яхшырту һәм хезмәтне саклау буенча район программасы кабул ителә, аны гамәлгә ашыру нәтиҗәсендә әлеге өлкәдә билгеле бер уңай үзгәрешләргә ирешелде.

Югарыда әйтелгәннәр районда хезмәтне саклау проблемаларын хәл итүнең программа методын дәвам итүнең нәтиҗәлелеген һәм кирәклеген раслый.

## II. Программаның максаты һәм төп бурычлары, аны гамәлгә ашыру сроклары, Программаның нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары

2.1. Программаның максаты - Арча муниципаль районы территориясендә урнашкан оешмалар хезмәткәрләренең һөнәри имгәнүләрен киметү максатларында хезмәт шартларын яхшырту һәм аны саклау.

2.2. Программаның төп бурычлары.

2.2.1. Хезмәтне саклау буенча дәүләт идарәсе системасын үстерү.

2.2.2. Заманча укыту технологияләре нигезендә хезмәтне саклау буенча хезмәткәрләр әзерләү.

2.2.3. Хезмәтне саклауны мәгълүмати тәэмин итү һәм пропагандалау.

2.3. Программаның максатлары һәм бурычлары буенча нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары. Куелган бурычларны хәл итүнең нәтиҗәлелеге түбәндәге индикатор күрсәткечләренә ирешүдә чагыла:

2.3.1. Хезмәтне саклау буенча дәүләт идарәсе системасын үстерү. Мәсьәләне чишүнең нәтиҗәсе булып «хезмәтне саклау чараларына 1 кешегә исәпләгәндә 9500 сумга кадәр чыгымнар» индикаторы күрсәткеченә ирешү тора.

2.3.2. Заманча укыту технологияләре нигезендә хезмәтне саклау буенча хезмәткәрләр әзерләү.

Мәсьәләне чишүнең нәтиҗәсе булып «җитәкчеләрнең һәм белгечләрнең хезмәтне саклау буенча узган уку дәрәҗәсе 1000 эшләүчегә исәпләгәндә 29,5 кешегә кадәр» индикаторы күрсәткеченә ирешү тора.

2.3.3. Хезмәтне саклауны мәгълүмати тәэмин итү һәм пропагандалау.

Мәсьәләне чишүнең нәтиҗәсе булып «производствода зыян күрүчеләр

саны 1000 эшләүчегә 1,1 кешегә кадәр» индикаторы күрсәткечենә ирешү тора.

2.4. Программаны гамәлгә ашыру вакыты- 2022-2025 еллар.

## IV. Программаны ресурслар белән тәэмин итүне нигезләү

Программаны финанслау район бюджетыннан һәм Арча муниципаль районы предприятиеләре һәм оешмалары акчаларыннан гамәлгә ашырылачак, гомуми күләме- 61383,0 мең сум, шул исәптән район бюджетыннан - 120,0 мең сум:

2022 елда -14729,0 мең сум, шул исәптән район бюджетыннан - 30,0 мең сум;

2023 елда -15129,0 мең сум, шул исәптән район бюджетыннан - 30,0 мең сум;

2024 елда -15527,0 мең сум, шул исәптән район бюджетыннан - 30,0 мең сум;

2025 елда -15998,0 мең сум, шул исәптән район бюджетыннан - 30,0 мең сум.

## V. ПРОГРАММАНЫ ГАМӘЛГӘ АШЫРУ МЕХАНИЗМЫ

Программаны гамәлгә ашыру белән идарә итүне Арча муниципаль районы Башкарма комитеты каршындагы Хезмәтне саклау буенча координация советы башкара.

Хезмәтне саклау буенча координация советы:

Программа чаралары исемлеген, Программа чаралары буенча чыгымнарны һәм Программаны гамәлгә ашыру механизмын әзерләү һәм төгәлләштерү эшчәнлеген координацияли;

Программаның максатчан индикаторлары һәм нәтиҗәлелеге күрсәткечләре исемлеген төгәлләштерә;

Программаны гамәлгә ашыруның барышы турында хисап алып бара һәм аны Арча муниципаль районы Башкарма комитетына тапшыра.

## VI. Программаның социаль-икътисади нәтиҗәлелеген бәяләү

Арча муниципаль районы бюджеты чыгымнарының нәтиҗәлелеген бәяләү оч төп юнәлеш буенча алып барыла: потенциаль икътисади нәтиҗәләр, нәтиҗәләргә ирешүнең нәтиҗәлелеге, социаль-икътисади нәтиҗәлелек.

Чыгымнарның потенциаль икътисади нәтиҗәлелеге Программаны гамәлгә ашыруга тотылган чыгымнарның килгән зыянның суммасына карата нисбәте буларак билгеләнә.

Нәтиҗәләргә ирешү нәтиҗәлелеге халыкның тормыш сыйфатын бәяләү индикаторларының иң чик күрсәткечләренә ирешү белән билгеләнә:

хезмәтне саклау чараларына чыгымнарны 1 кешегә исәпләгәндә 9500 сумга кадәр арттыру;

производствода имгәнүләр дәрәҗәсен 1000 эшләүчегә 1,1 кадәр киметү;

җитәкчеләрнең һәм белгечләрнең (1000 хезмәткәргә исәпләгәндә) хезмәтне

саклау буенча укуларын 31,5 кә кадәр арттыру.

Программаның социаль-икътисади нәтиҗәлелеге түбәндәге күрсәткечләр белән бәяләнә:

производствода бәхетсезлек очракларыннан, производствога бәйле авырулардан, һөнәри авырулардан зыян күргән хезмәткәрләрнең сәламәтлеген торгызуга матди чыгымнарны киметү;

производствода бәхетсезлек очраклары һәм һөнәри авырулар нәтиҗәсендә хезмәткәрләргә килгән зыянны каплауга чыгымнарны киметү;

авыр хезмәт шартларында, зарарлы һәм куркыныч хезмәт шартларында эшләгән өчен ташламалар һәм компенсацияләр бирүгә чыгымнарны киметү;

моңа бәйле рәвештә сәламәтлек саклау өлкәсендә производствода имгәнүләр яисә һөнәри авыру нәтиҗәсендә инвалидлыкка чыгымнарны киметү;

эш вакытын югалтуларны кыскарту исәбенә хезмәт җитештерүчәнлеген арттыру;

имгәнүләр һәм производствога бәйле авырулар аркасында төп хезмәткәрләрне алмаштыручы, эш тәҗрибәсе һәм квалификациясе җитәрлек булмаган вакытлыча эшчеләр тарафыннан ватылган җиһазларны ремонтлауга һәм алыштыруга киткән чыгымнарны киметү.

## III. 2022-2025 елларга Арча муниципаль районында хезмәт шартларын яхшырту һәм хезмәтне саклау буенча программа чаралары исемлеге

| № | Программа чаралары исеме | Башкаручылар | Финанс чыгымнары, мең сум | | | | | Финанслау чыгнаклары |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | барлыгы | 2022 ел | 2023 ел | 2024 ел | 2025 ел | |
| | **1. Хезмәтне саклау шартларын норматив-хокукый тәэмин итү** | | | | | | | |
| 1.1 | Авыл хуҗалыгы эшләрен уздыруның аерым чорларына кулланмалар, нигезләмәләр, киңәшләр эшләү | Башкарма комитет, Арча муниципаль районында авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе | 486 | 121 | 120 | 122 | 123 | Башкарма комитет акчалары |
| 1.2 | Барлык милек формаларындагы предприятиеләр һәм оешмаларны хезмәтне саклау һәм аның шартлары буенча норматив-методик хокукый актлар белән тәэмин итү | ТР Хезмәт, мәшгульлек һәм социаль яклау министрлыгы<br>ТР Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы «МАОТ» | 828 | 205 | 208 | 206 | 209 | Республика бюджеты акчалары |
| | **2. Хезмәт шартларын һәм хезмәтне саклауны оештыру һәм техник тәэмин итү** | | | | | | | |
| 2.1 | 2019-2021 елларда хезмәт шартларын яхшырту һәм хезмәтне саклау буенча территориаль программа эшләү | Башкарма комитет, Хезмәтне саклау буенча координация советы, предприятиеләр һәм оешмалар | | | | | | Район бюджеты, предприятиеләр һәм оешмалар акчалары |
| 2.2 | РФ Хезмәт кодексының 217 нче ст. нигезендә муниципаль район предприятиеләрен хезмәтне саклау буенча белгечләр белән тәэмин итү | Башкарма комитет, Хезмәтне саклау буенча координация советы, предприятиеләр һәм оешмалар | 3306 | 824 | 827 | 825 | 830 | Предприятиеләр һәм оешмалар акчалары |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 2.3 | Муниципаль район предприятиеләрендә хезмәтне саклау буенча кабинетлар һәм почмаклар булдыру (яңарту) | Башкарма комитет, Хезмәтне саклау буенча координация советы, предприятиеләр һәм оешмалар | 1821 | 495 | 422 | 442 | 462 | Предприятиеләр һәм оешмалар акчалары |
| 2.4 | Хезмәтне саклау (шул исәптән предприятиеләргә чыгып) буенча семинар-киңәшмәләр үткәрү | Башкарма комитет, Хезмәтне саклау буенча координация советы, Роспотребнадзор | 472 (шул исәптән 30 район бюджетыннан) | 117 (шул исәптән 10 район бюджетыннан) | 113 (шул исәптән 10 район бюджетыннан) | 120 (шул исәптән 10 район бюджетыннан) | 122 (шул исәптән 10 район бюджетыннан) | Район бюджеты акчалары |
| 2.5 | Барлык оештыру-хокукый формадагы предприятиеләр арасында хезмәтне саклау эшен иң яхшы оештыруга смотр-конкурс үткәрү | Башкарма комитет, Хезмәтне саклау буенча координация советы | 496 (шул исәптән 30 район бюджетыннан) | 118 (шул исәптән 10 район бюджетыннан) | 126 (шул исәптән 10 район бюджетыннан) | 125 (шул исәптән 10 район бюджетыннан) | 127 (шул исәптән 10 район бюджетыннан) | Район бюджеты акчалары |
| 2.6 | Район учреждениеләрендә, авыл хуҗалыгы предприятиеләрендә, оешмаларында хезмәт шартларын махсус бәяләүне (СОУТ) үткәрү эшен оештыру | Башкарма комитет, Хезмәтне саклау буенча координация советы, предприятиеләр һәм оешмалар | 3609 | 861 | 1081 | 727 | 940 | ФСС, район бюджеты, предприятеләр предприятиеләр һәм оешмалар акчалары |
| | **3. Район оешмаларында хезмәт шартларының һәм хезмәтне саклауның торышын яхшырту** | | | | | | | |
| 3.1 | Район предприятиеләрендә хезмәткәрләрнең имин һәм сәламәт хезмәт шартларына хокукларын яклауны тәэмин итү | Башкарма комитет, Арча муниципаль районында авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе, барлык милек | | | | | | |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | формаларындагы предприятие һәм оешмалар житәкчеләре | | | | | | |
| 3.2 | Районда предприятиеләрне имин хезмәт шартлары тудыру, куркынычсыз техника һәм технология, хосусый һәм күмәк яклау чараларын эшләү һәм гамәлгә кертү буенча икътисади стимуллаштыруны күздә тоту | Башкарма комитет, Арча муниципаль районында авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе предприятиеләр һәм оешмалар | 1585 | 349 | 387 | 418 | 431 | Район бюджеты, предприятеләр акчалары |
| 3.3 | Имгәнү торышын һәм аны кисәтү буенча кабул ителә торган чараларның нәтиҗәлелеген анализлау (ел нәтиҗәләре буенча) | Хезмәтне саклау буенча координация советы | | | | | | |
| 3.4 | Район предприятиеләрендә һәм оешмаларында хезмәтне саклау торышына үзара тикшерүләр үткәрүне оештыру | Башкарма комитет, Арча муниципаль районында авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе | | | | | | |
| 3.5 | Хезмәт шартларын яхшырту максатында район предприятиеләрендә эш урыннарына СОУТ оештыруда ярдәм итү | Башкарма комитет, Хезмәтне саклау буенча координация советы | | | | | | |
| 3.6 | Хезмәтне саклау буенча килешүләрдә (күмәк шартнамәләрдә) түбәндәгеләрне күздә тотарга:<br>- хезмәткәрләрнең иминлеген тәэмин итә торган саклану чаралары белән тулысынча тәэмин итү;<br>- эшләүче хатын-кызларны физик эшләрдән азат итү максатында механикалаштыру чаралары сатып алу | Предприятиеләр, оешмалар | | | | | | |
| | **4. Җитештерүдә имгәнүләр һәм һөнәри авырулар дәрәҗәсен киметү** | | | | | | | |
| 4.1 | Авыл хуҗалыгы предприятиеләре, кече бизнес | МАОТ, | 1753 | 477 | 409 | 412 | 455 | ФСС, |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | предприятиеләре, бюджет учреждениеләре һәм башка оешмалар җитәкчеләренең, белгечләренең һәм вәкаләтле затларның хезмәтне саклау буенча укулары | Башкарма комитет, Хезмәтне саклау буенча координация советы | | | | | | Татарстан Республикасы бюджеты, предприятиеләр һәм оешмалар акчалары |
| 4.2 | Хезмәтне саклау буенча квартал саен статистик күзәтүне тәэмин итү (хезмәтне саклауның 1 нче формасы буенча) | Дәүләт статистика бүлеге | | | | | | |
| 4.3 | Оешмалар хезмәткәрләренең профилактик медицина тикшерүен тәэмин итү | «Арча үзәк район хастаханәсе» ДАССУ предприятиеләр, оешманың | 11567 | 2710 | 2769 | 3008 | 3080 | Предприятеләр предприятиеләр, ФСС акчалары |
| 4.4 | Зарарлы һәм куркыныч хезмәт шартларында эшләүчеләрне махсус кием, аяк киеме һәм башка СИЗ белән тәэмин итү | Предприятиеләр, оешмалар | 28351 | 6807 | 6966 | 7276 | 7302 | Предприятеләр предприятиеләр, ФСС акчалары |
| 4.5 | Предприятиеләрне хезмәтне саклау буенча норматив документлар белән тәэмин итү | Башкарма комитет, предприятиеләр, оешмалар | 469 | 113 | 118 | 117 | 121 | Республика бюджеты, предприятиеләр акчалары |
| 4.6 | Хезмәтне саклау буенча инструктажлар программасын эшләү һәм аларны вакытында гамәлгә кертү | Предприятиеләр һәм оешмалар | | | | | | Предприятеләр акчалары |
| 4.7 | Хезмәтне саклау буенча җитешмәгән инструкцияләрне эшләү, раслау һәм аларны вакытында гамәлгә кертү (файдалану). | Предприятиеләр һәм оешмалар | 681 | 193 | 155 | 161 | 172 | Предприятеләр акчалары |
| 4.8 | Хезмәтне саклау көннәре, хезмәт куркынычсызлыгы айлыклары үткәрү, «Арча хәбәрләре» район газетасында хезмәтне саклау мәсьәләләрен пропагандалау (оператив мәгълүмат, хезмәтне саклау буенча норматив | Башкарма комитет, Хезмәтне саклау буенча координация советы, предприятиеләр, оешмалар | 1029 (шул исәптән 30 район | 240 (шул исәптән 10 район | 254 (шул исәптән 10 район | 265 (шул исәптән 10 район | 270 (шул исәптән 10 район | Район бюджеты, предприятиеләр һәм оешмалар акчалары |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | документлар бастырып чыгару) | | бюджет ыннан) | бюдже тынна н) | бюдже тынна н) | бюджет ыннан) | бюдже тынна н) | |
| | **5. Хатын-кызларның хезмәт шартларын яхшырту һәм аларны акрынлап авыр һәм зарарлы хезмәт шартларындагы эштән азат итү** | | | | | | | |
| 5.1 | Хатын-кыз-терлекчеләрнең эш урыннарын гамәлдәге санитар-гигиена нормативлары нигезендә механикалаштырылган чаралар белән җиһазлау | Башкарма комитет, хуҗалыклар җитәкчеләре | 1566 | 333 | 380 | 423 | 430 | Предприятеләр акчалары |
| 5.2 | Предприятиеләрдә хезмәткәрләргә сәламәтлекләренә зыян китерми торган хезмәт һәм санитар-көнкүреш шартлары тудыру | Башкарма комитет, Роспотребнадзор, предприятиеләр, оешмалар | 489 | 123 | 122 | 120 | 124 | Предприятеләр акчалары |
| 5.3 | Предприятиеләр һәм оешмаларның электр белән эретеп ябыштыручыларына зарарлы газлардан саклану өчен саклагыч битлекләр сатып алу | Предприятиеләр һәм оешмалар | 1021 | 239 | 237 | 265 | 280 | Предприятеләр акчалары |
| 5.4 | Башкарма хакимият органнарына, җирле үзидарә органнарына хатын-кызларны авыр һәм зарарлы хезмәт шартлары булган эшләрдән азат итү турында тәкъдимнәр әзерләү һәм кертү (хезмәткәрләрне күпләп азат иткән һәм аларны алга таба эшкә урнаштырырга кыен булган очракларда) | «Арча районы халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» ДКУ | | | | | | Агымдагы финанслау кысаларында |
| 5.5 | Халыкны эш белән тәэмин итү органнарына ярдәм сорап мөрәҗәгать иткән бала тудыру яшендәге хатын-кызларга халыкны эш белән тәэмин итү органнары тарафыннан күрсәтелә | «Арча районы халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» ДКУ | | | | | | Агымдагы финанслау кысаларында |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | торган хезмәтләр һәм хезмәт базары торышы турында мәгълүмат бирү | | | | | | | |
| 5.6 | Махсус программалардан файдаланып, мәшгульлеккә ярдәм итү | «Арча районы халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» ДКУ | | | | | | Агымдагы финанслау кысаларында |
| 5.7 | Зарарлы һәм авыр хезмәт шартларында эшләүчеләрне шифаханә-курорт дәвалануы өчен юлламалар белән тәэмин итү | Предприятиеләр һәм оешмалар | 1854 | 404 | 435 | 495 | 520 | ФСС, предприятиеләр һәм оешмалар акчалары |
| 5.8 | Эштән азат ителгән зарарлы һәм авыр хезмәт шартларында эшләгән һәм билгеләнгән тәртиптә эшсез дип танылган хатын-кызларны һөнәри яңадан укытуны оештыру | «Арча районы халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» ДКУ | | | | | | Агымдагы финанслау кысаларында |
| | **Программа буенча барлыгы** | | **61383,0** | **14729,0** | **15129,0** | **15527,0** | **15998,0** | |